Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Биляр-Озеро авыл җирлегенең Биляр-Озеро авылы торак пунктында гражданнар җыены КАРАРЫ

«15» ноябрь 2020 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Биляр-Озеро авыл җирлегенең Биляр-Озеро авылы торак пункты гражданнары җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә», 2020 елның 15 ноябрендә узган: «Биляр-Озеро авыл җирлеге Биляр-Озеро торак пункты территориясендә яшәүче, 1 гр инвалидларыннан тыш, 2 төркем инвалидлар (I һәм II дәрәҗә хезмәт эшчәнлегенә сәләте чикләнгән очракта),балачактан инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан кала балигъ булган һәр кешедән 2021 елда 1000 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару өчен җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- торак пункт чикләрендә авыл эчендәге юлларны карап тоту һәм ремонтлау, шул исәптән сезонлы карап тоту;

- су белән тәэмин итү чыганакларын норматив таләпләр белән тәэмин итү эшләрен үткәрү;

- янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү өчен цистерна сатып алу;

- урамнарны яктыртуны оештыруны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр һәм хезмәтләр сатып алу.

Халык җыенында рәислек итүче: И.М.Шәрәфетдинов

Биляр-Озеро авыл җирлеге башлыгы: И.М. Шәрәфетдинов